КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 18 июнь г.Казань № 436

«Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында контракт буенча хәрби хезмәт узучы гражданнарга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Рәисенең «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында контракт буенча хәрби хезмәт узучы гражданнарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2024 елның 8 маендагы 325 номерлы Указын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында контракт буенча хәрби хезмәт узучы гражданнарга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен (алга таба - Тәртип) расларга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән чыгымнарны финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары булуын билгеләргә.

3. Казан шәһәре контракты буенча хәрби хезмәткә (1 разрядлы) сайлап алу пунктына һәм Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына Тәртипкә нигезләнеп эш итүне тәкъдим итәргә

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2022 ел, 11 июль, 663 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затларга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2022 ел, 11 июль, 663 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затларга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2022 ел, 20 июль, 697 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затларга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2022 ел, 11 июль, 663 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затларга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 13 август, 811 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затларга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2022 ел, 11 июль, 663 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затларга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2022 ел, 31 октябрь, 1153 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затларга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2022 ел, 11 июль, 663 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затларга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 30 декабрь, 1476 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затларга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2022 ел, 11 июль, 663 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затларга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2023 ел, 25 декабрь, 1681 нче.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры вазыйфаларын
башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 18 июнь, 436 нчы карары белән расланды

«Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында контракт буенча хәрби хезмәт узучы гражданнарга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибе

1. Әлеге Тәртип контракт буенча хәрби хезмәткә кергән һәм контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алу пункты (1 разряд), Казан шәһәре яисә Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты тарафыннан «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарына җибәрелгән гражданнарга бер тапкыр акчалата түләү (алга таба - бер тапкыр түләү) бирү механизмын билгели.

2. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты белән берлектә, Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разрядлы) сайлап алу пункты тарафыннан әлеге Тәртипкә кушымтада бирелгән форма буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) җибәрелә торган исемлекләр (алга таба – исемлекләр) нигезендә 360,0 мең сум күләмендә бирелә.

Бер тапкыр бирелә торган түләү бер тапкыр бирелә.

3. Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разрядлы) сайлап алу пункты, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты белән берлектә, әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә Министрлыкка бирелә торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплы.

4. Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разрядлы) сайлап алу пункты, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты белән берлектә, «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнардан аларның шәхси белешмәләрен Министрлык тарафыннан эшкәртүгә һәм Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разрядлы) сайлап алу пунктына башкарылган түләүләр турында белешмәләр тапшыруга ризалык алуны тәэмин итә.

5. Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты белән берлектә, Министрлык, Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разрядлы) сайлап алу пункты, әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнарның алынган шәхси мәгълүматлары конфиденциальлеген һәм сакланышын тәэмин итә, аларны хокуксыз файдаланган өчен күрсәтелгән Федераль закон нигезендә җавап бирә.

6. Әлеге Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнарның кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү суммаларын күчерү Министрлык тарафыннан, Министрлыкка исемлекләр кергән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә башкарыла.

7. Министрлык хисап елынннан соң килә торган елның 20 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына бер тапкыр бирелә торган түләүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап тапшыра.

«Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында контракт буенча хәрби хезмәт узучы гражданнарга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә кушымта

Форма

Раслыйм
Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә (1 разрядлы) сайлап алу пункты башлыгы

___________ ______________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

20__ ел, «__» ___________

Килештерелде
Татарстан Республикасы Хәрби комиссары

__________ _______________________________
( имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

20__ ел, «__» ___________

Контракт буенча хәрби хезмәткә кергән һәм контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алу пункты (1 разряд), Казан шәһәре яисә Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты тарафыннан «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарына җибәрелгән гражданнар исемлеге

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Кредит оешмасының исеме | Кредит оешмасы-ның ИНН/КПП ы | Кредит оешмасының БИКы | Кредит оешмасындагы шәхси счет номеры |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | | | | | |

Башкаручы _________________ ______________________ ________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))
М.У.

___________________________